| УКАЗ<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>УКАЗЫ |
|---|---|---|

**Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия аппараты эшчәнлеге оештыру һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия аппараты эшчәнлеген оештыру максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президенты Аппараты структурасында, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты хезмәткәрләре чик санын үзгәрешсез калдырып, Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы эшчәнлеген тәэмин итү бүлеген төзергә.

2. Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге мөдире Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия аппараты җитәкчесе функцияләрен башкара дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия аппараты вазыйфалар буенча составын расларга (1 нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенә, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесенә Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия аппараты составына кертелгән затларның вазыйфаи регламентларына, әлеге Указның нигезләмәләрен һәм Россия Федерациясе субъектындагы террорчылыкка каршы комиссия аппараты хезмәткәренең вазыйфаи регламенты эчтәлегенә карата Террорчылыкка каршы милли комитет тарафыннан хупланган тәкъдимнәрне исәпкә алып, үзгәрешләр кертүне тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия утырышларын әзерләү һәм уздыру белән бәйле материаллар, шулай ук Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия эшчәнлеген оештыру һәм матди-техник тәэмин итү буенча башка документлар Татарстан Республикасы Президенты Аппаратында саклана дип билгеләргә.

6. Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенә:

законнарда билгеләнгән вакытта һәм тәртиптә әлеге Указны гамәлгә ашыру буенча оештыру-штат чараларын уздырырга;

ике ай вакыт эчендә Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге турындагы нигезләмәне әзерләргә һәм раслауга кертергә.

7. Әлеге Указның 6 пунктында каралган оештыру-штат чаралары тәмамланганчы, Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының әлеге чаралар кагыла торган хезмәткәрләре, аларның ризалыгы булганда, элек биләгән вазыйфалары буенча хезмәт вазыйфаларын үтәүләрен дәвам итәләр дип билгеләргә.

8. Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына исемлек нигезендә үзгәрешләр кертергә (2 нче кушымта).

9. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында террорчылыкка каршы комиссия эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре турында» 2006 елның 4 апрелендәге ПУ-128 номерлы Указының (Татарстан Республикасы Президентының 2006 елның 18 августындагы ПУ-314 номерлы, 2007 елның 3 декабрендәге ПУ-645 номерлы, 2008 елның 5 сентябрендәге ПУ-443 номерлы, 2009 елның 17 апрелендәге ПУ-205 номерлы, 2009 елның 22 июнендәге ПУ-342 номерлы, 2010 елның 22 мартындагы ПУ-157 номерлы, 2010 елның 3 июнендәге ПУ-362 номерлы, 2011 елның 1 июнендәге ПУ-299 номерлы, 2011 елның 15 августындагы ПУ-504 номерлы, 2012 елның 14 мартындагы ПУ-203 номерлы, 2012 елның 23 июнендәге ПУ-496 номерлы, 2012 елның 29 декабрендәге ПУ-1139 номерлы, 2013 елның 9 октябрендәге ПУ-1007 номерлы, 2014 елның 22 февралендәге ПУ-198 номерлы, 2014 елның 9 июнендәге ПУ-566 номерлы, 2014 елның 27 августындагы ПУ-825 номерлы, 2014 елның 15 октябрендәге ПУ-986 номерлы, 2014 елның 1 ноябрендәге ПУ-1015 номерлы һәм 2015 елның 7 июлендәге ПУ-624 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 2 пунктының икенче абзацы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссиянең персональ составына үзгәрешләр кертү турында» 2006 елның 18 августындагы ПУ-314 номерлы Указының 2 пункты;

«Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 9 июнендәге ПУ-566 номерлы Указының 2 пункты.

10. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел, 21 июль
№ ПУ-668

Татарстан Республикасы
Президентының
2015 елның «21» июлендәге
ПУ-668 номерлы Указына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия аппараты вазыйфалар буенча составы**

1. Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге мөдире, Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия аппараты җитәкчесе.
2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Административ һәм хокук саклау органнары идарәсе башлыгы, Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия аппараты җитәкчесе урынбасары.
3. Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты Дини берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек идарәсенең дәүләт-конфессиональ мөнәсәбәтләр бүлеге мөдире, Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия аппараты җитәкчесе урынбасары.
4. Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге баш киңәшчесе.
5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Административ һәм хокук саклау органнары идарәсе башлыгы урынбасары.
6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Административ һәм хокук саклау органнары идарәсенең хокук саклау органнары белән үзара хезмәттәшлек секторы мөдире.
7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Административ һәм хокук саклау органнары идарәсенең административ органнар белән үзара хезмәттәшлек секторы мөдире.
8. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Административ һәм хокук саклау органнары идарәсенең хокук саклау органнары белән үзара хезмәттәшлек секторы баш киңәшчесе.
9. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Административ һәм хокук саклау органнары идарәсенең административ органнар белән үзара хезмәттәшлек секторы баш киңәшчесе.

Татарстан Республикасы
Президентының
2015 елның « 21 » июлендәге
ПУ-668 номерлы Указына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлеге**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты турында» 2006 елның 5 апрелендәге ПУ-134 номерлы Указының (Татарстан Республикасы Президентының 2006 елның 16 июнендәге ПУ-223 номерлы, 2006 елның 10 ноябрендәге ПУ-466 номерлы, 2007 елның 21 июнендәге ПУ-323 номерлы, 2008 елның 29 августындагы ПУ-425 номерлы, 2010 елның 12 мартындагы ПУ-121 номерлы, 2010 елның 1 апрелендәге ПУ-183 номерлы, 2010 елның 12 июлендәге ПУ-445 номерлы, 2010 елның 25 декабрендәге ПУ-863 номерлы, 2011 елның 15 гыйнварындагы ПУ-7 номерлы, 2011 елның 30 ноябрендәге ПУ-774 номерлы, 2012 елның 30 июлендәге ПУ-624 номерлы, 2012 елның 13 августындагы ПУ-649 номерлы, 2012 елның 19 октябрендәге ПУ-880 номерлы, 2013 елның 18 гыйнварындагы ПУ-31 номерлы, 2013 елның 1 февралендәге ПУ-74 номерлы, 2013 елның 18 маендагы ПУ-420 номерлы, 2013 елның 21 сентябрендәге ПУ-925 номерлы, 2013 елның 30 октябрендәге ПУ-1065 номерлы һәм 2013 елның 14 декабрендәге ПУ-1214 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 1 пунктына:

а) түбәндәге эчтәлекле унтугызынчы абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге;»;

б) унтугызынчы – егерме өченче абзацларны тиешенчә егерменче – егерме дүртенче абзацлар дип санарга.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты структурасына һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 30 октябрендәге ПУ-1065 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 14 декабрендәге ПУ-1214 номерлы, 2013 елның 14 декабрендәге ПУ-1215 номерлы, 2014 елның 20 августындагы ПУ-797 номерлы, 2014 елның 1 октябрендәге ПУ-949 номерлы, 2014 елның 17 ноябрендәге ПУ-1052 номерлы һәм 2015 елның 26 июнендәге ПУ-602 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты Аппараты структурасында һәм хезмәткәрләренең чик санында:

а) 2-7 позицияләрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2 | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе | 7 | * |
| 3 | Татарстан Республикасы Президенты референты | 3 | |
| 4 | Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советында тулы вәкаләтле вәкиле | ** | |
| 5 | Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы Секретаре | 1 | |
| 6 | - | - | |
| 7 | - | - | |
| | **Барлыгы** | **11** | |

»;

б)

«

| | | | |
|---|---|---|---|
| 23 | Баш киңәшче | 8 | |

»

позициясен түбәндәге эчтәлекле позициягә алмаштырырга:

«

| | | | |
|---|---|---|---|
| 23 | Баш киңәшче | 7 | |

»;

в) 25 позициясеннән соң килүче «Идарә буенча барлыгы» позициясендәге «Берәмлекләр саны» графасында «14» санын «13» санына алмаштырырга;

г)

«

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсе буенча барлыгы** | **36** | |

»

позициясеннән соң түбәндәге эчтәлекле позицияләр һәм сүзләр өстәргә:

**«Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 118 | Бүлек мөдире | 1 | |
| 119 | Баш киңәшче | 2 | |
| 120 | I категория белгеч | 1 | *** |
| | **Барлыгы** | **4** | |

».

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия аппараты турында» 2015 елның 15 июнендәге ПУ-550 номерлы Указында:

а) рус текстында «Аппаратта» сүзен «аппаратта» сүзенә алмаштырырга;

б) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия аппаратын төзергә.

Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия аппараты Террорчылыкка каршы милли комитет рәисе тарафыннан расланган Россия Федерациясе субъектында Террорчылыкка каршы нигезләмә һәм Россия Федерациясе субъектында террорчылыкка каршы комиссия регламенты нигезендә Татарстан Республикасында

Террорчылыкка каршы комиссия эшчәнлеген оештыру ягыннан һәм матди-техник яктан тәэмин итүне башкара.».

в) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия аппараты җитәкчесе вазыйфаларын башкаруны Галиев Илдар Шамил улына йөкләргә.».